**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Колбай-Мораса ав. **КАРАР**

«20» октябрь 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Колбай-Мораса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 5 ноябрендә 13 сәгать 30 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Колбай-Мораса авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә

2. Колбай-Мораса авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыруны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Колбай-Мораса авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин